**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.12.2025 № 1516

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 03 маендагы 321 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 996 номерлы карары, социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсенең Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне тәртипкә китерү максатларында бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча тариф челтәре нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 гыйнварыннан ««Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 3 маендагы 321 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 02.07.2024 № 712, 24.10.2025 № 1190 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәй тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен әлеге карарның 1 пункты нигезендә муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсе аерым оешмасының бердәй тариф челтәре кагылмый торган структур бүлекчәсе җитәкчесе секретареның вазыйфаи оклады күләмен Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүне 1,1 тапкырга индексацияләргә һәм аны 16 928 сум күләмендә билгеләргә.

3. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет

палатасы»  муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

4. Аерым оешмаларның җитәкчеләренә элек чыгарылган актларны әлеге карарга туры китерергә.

5. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин